СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ 19.08.2019 — КАРАР № 48-544

с. Верхний Услон

**Югары Ослан муниципаль районында мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе турында Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 01.04.2002 ел, №163 **“**Татарстан Республикасында мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе турында Кагыйдәнамә” Карарына нигезләнеп,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**

**Карар чыгарды:**

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының 2018 елның 5 июлендәге №35-391 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында мемориаль такталар урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 7.2 пунктында «Муниципаль заказлар» сүзләрен «сатып алу» сүзенә алмаштырырга.

2. Югары Ослан муниципаль районында мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе турында Кагыйдәнамә расларга (Кушымта №1)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының иҗтимагый –мәдәният һәм яшьләр эшләре комиссияләренә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Башлыгы** **М.Г. Зиатдинов**

Югары Ослан муниципаль районы
Советының № 48-544,
19.08 2019 карарына
Кушымта №1

**Югары Ослан муниципаль районында мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе турында Кагыйдәнамә**

## 1. Гомуми кагыйдәнамәләр.

1.1. Мемориаль такта Ватан алдында күрсәткән хезмәтләре өчен, үзләренең эшчәнлекләре белән Россия Федерациясенә, Татарстан Республикасына, Югары Ослан муниципаль районы тормышындагы әһәмиятле тарихи вакыйгалар һәм даталар, фән һәм техника, мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәсендә, гражданнарның тормышы һәм хокукларын саклауга күпъеллык хезмәтләре белән файда китергән шәхесләрнең исемен мәңгеләштерүче тарих һәйкәле булмаган ( сәнгать мәгънәсеннән кала, монументаль сәнгать объектына караган очракта), хәтер билгесе булган монументаль сәнгатьнең бер төре.

Шәхесләрнең исемен мәңгеләштерү турында Кагыйдәнамә буенча биналарда, корылмаларда, яки торак йортларда куелган башка теләсә кайсы мәгълүмат билгесе (такта) мемориаль була алмый.

1.2. Мемориаль такталар бинаның алгы ягында, корылмаларда, кайвакыт бинаның эчке ягында, торак йортларда, тарихи вакыйгалар булган урыннарда, танылган шәхесләр эшләгән һәм яшәгән урыннарда, шулай ук танылган шәхесләр, тарихи вакыйга исемнәре бирелгән урамнарда урнаштырыла.

1.3. Мемориаль такталар бинаның алгы ягында, корылмаларда, бу бина юридик һәм физик затларның милек хокуы булган очракта, хуҗалык алып барганда һәм оператив идарә иткәндә аларның ризалыгы буенча урнаштырыла ала.

1.4. Мемориаль такталарның тексты Татарстан Республикасындагы дәүләт телләрендә – татар һәм рус телләрендә язылырга тиеш.

1.5. Мемориаль такталарны кую белән Россия Федерациясе гражданнары кебек башка дәүләт гражданнарының исемнәре дә мәңгеләштерелә.

1.6. Мемориаль такталарны урнаштыру МКУ“Югары Ослан муниципаль районы Мәдәният бүлеге” тәкъдим иткән материаллар нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты Кагыйдәнамәсе белән тормышка ашырыла.

1.7. Мемориаль такталарны проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыру эшләре буенча заказ бирүче булып Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

1.8. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе турында Кагыйдәнамәсе Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла.

**II. Гражданнарның исемен һәм вакыйгаларны мәңгеләштерү өчен нигез.**

2.1. Мемориаль такталарны урнаштыру турында карар кабул итүгә нигез булып:

вакыйганың Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы тарихында әһәмиятле булуы;

дәүләт, җәмгыять, сәясәт, хәрби, фән һәм техника, әдәбият, сәнгать, мәдәният, спорт, җитештерү эшчәнлегендә казанышларның булуы, шулай ук шәхеснең Югары Ослан муниципаль районы халкында зур танылу алуы , Россия Федерациясенә,Татарстан Республикасына, Югары Ослан муниципаль районына файда китерүе тора.

2.2. Мемориаль такталар гражданнар хөрмәтенә урнаштырыла ала:

төрле өлкәләрне үстерүгә керткән зур өлеше өчен һәм дәүләт бүләге булган очракта;

Югары Ослан муниципаль районы, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы тормышы өчен башкарган героик һәм башка танылган эшләре өчен.

**III. Мемориаль такталарны урнаштыру тәртибе**

3.1**.** Вакыйганың яки шәхеснең тарихи һәм мәдәни әһәмияткә ия булуын объектив бәяләү максатыннан, мемориаль такталар:

исеме мәңгеләштереләчәк зат үлгәннән соң кимендә 1 ел узгач ;

аның истәлеген мәңгеләштерү вакыйгасыннан соң 5 ел узгач урнаштырыла.

3.2. Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерына мемориаль такта үлеменнән соң соңгы елларда яшәгән йортында, яки пенсиягә (отставкага) чыкканчы эшләгән һәм хезмәт иткән оешма бинасына урнаштырыла.

## IV. Мемориаль такталарның тышкы күренешенә таләпләр

4.1. Мемориаль такталар нык материаллардан (мәрмәр, гранит, чуен, бакыр һәм башка материаллардан) эшләнә.

4.2. Мемориаль тактаның тексты кыска һәм ачык итеп, мемориаль такта багышланган шәхеснең казанышлары, уңышлары, тормыш (эшчәнлек) чоры турында мәгълүматлар белән языла.

4.3. Шәхес хөрмәтенә куелачак мемориаль тактаның текстында аның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (сакланса) күрсәтелә.

4.4. Мемориаль тактаның композициясенә, тексттан тыш, портрет сурәте, декаратив элементлар кертелә ала.

## V. Мемориаль тактаны урнаштыру турында юллама белән эшләү тәртибе

5.1. Мемориаль тактаны урнаштыру буенча башлап йөрүче (алда-башлап йөрүче) булып дәүләт власте органнары, җирле үзидарә органнары, милек формасы иреклe оешмалар, шулай ук 10 кешедән торган төркем була ала.

5.2. Мемориаль тактаны урнаштыру буенча башлап йөрүче “Югары Ослан муниципаль районы Мәдәният бүлеге”нә түбәндәге документларны тапшыра:

мемориаль тактаны урнаштыру кирәклеге турында тулы дәлил белән гариза (юллама);

рәсми документлар нигезендә тулы биографик һәм тарихи белешмә;

исеме мәңгеләштереләчәк затның казанышлары һәм вакыйгаларның дөреслеген раслаучы архив һәм башка документларның күчерелмәсе;

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белгечләре раслаган телләрдә мемориаль тактаның текст проекты;

мемориаль тактаның эскизы;

мемориаль такта урнаштырылачак урын турында мәгълумат (мемориаль такта куелачак бинаның фотосурәте, торак урынының алгы ягы);

тиешле торак-файдалану оешмаларыннан исеме мәңгеләштереләчәк затның шушы йортта яшәгән вакытын күрсәтүче документлар;

мемориаль тактаны урнаштыру өчен йорт (бина) хуҗасының ризалыгы;

мемориаль такталарны проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыруга гомуми чыгымнар сметасы һәм аны финанслау чыганаклары;

башлап йөрүченең проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыру буенча, мемориаль такталарны тантаналы ачуны оештыру чаралары өчен түләү йөкләмәсе белән гарантияле хаты;

мемориаль такта шәһәр яки авыл җирлегендә урнаштырылган очракта, мемориаль такта урнаштырылачак җирлекнең вәкаләтле оешмасы һәм муниципаль район башлыгы ризалыгы;

5.3. Башлап йөрүче тапшырган документлар әлеге Кагыйдәнамәнең 5.2.пункты нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының мемориаль такталарны урнаштыру Комиссиясендә (алда-Комиссия) карала.

5.4. Комиссия турында Кагыйдәнамә һәм аның составы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Комиссия составына Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре, социаль-мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча (килешү буенча) Югары Ослан муниципаль районы Советы даими комиссиясе, МКУ“Югары Ослан муниципаль районы Мәдәният бүлеге”, мемориаль такта урнаштырылачак җирлекнең шәһәр, авыл җирлеге башлыклары (килешү буенча), иҗади һәм иҗтимагый оешмалар. Кирәк дип тапса, Комиссия үз эшенә төрле оешма һәм ведомство белгечләрен җәлеп итә ала.

5.5. Комиссия бер ай вакыт эчендә документларны тикшерә һәм документлар тапшырылгач бер ай вакыт аралыгында мемориаль тактаны урнаштыру турында карар кабул итә.

5.6. Комиссия мемориаль тактаны урнаштыру турында уңай карар кабул иткән очракта, МКУ“Югары Ослан муниципаль районы Мәдәният бүлеге” карар кабул итеп бер ай эчендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына туры килгән карар проектын тәкъдим итә.

Проектка теркәлә:

Комиссия утырышының беркетмәсе яки күчерелмәсе;

мәңгеләштереләчәк вакыйга һәм зат турында төп мәгълуматлар;
мемориаль тактаны якынча урнаштыру урыны турында мәгълумат;
мемориаль тактаны проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыру эшләре буенча финанс чыганаклары турында мәгълумат;
мемориаль такта урнаштырылачак җирлекнең шәһәр, авыл җирлеге башлыклары белән килешү.

Комиссия мемориаль тактаны урнаштыру турында тискәре карар кабул иткән очракта, башлап йөрүче карар кабул итеп 15 көн эчендә бу турыда хәбәр алырга тиеш.

## VI. Мемориаль такталарны урнаштыру, карап тору һәм исәптә тоту тәртибе.

6.1. Мемориаль такталарны урнаштыру урыны һәм күләме Комиссия утырышында карала һәм килешенә. Мемориаль такталарны урнаштыру биналарга, корылмаларга һәм инженер челтәрләренә зыян китерергә тиеш түгел.

6.2. Мемориаль такталарны урнаштыру турында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына карар кабул иткәч, башлап йөрүче аларны ясау һәм урнаштыру эшен башкара.

6.3. Кирәк булса (корылма һәм биналарның торышы начар булган очракта) башлап йөрүче мемориаль такталарны тантаналы ачу вакыйгасына кадәр корылма, биналарны төзәтү эшләре башкара.

6.4. Торак һәм торак булмаган биналарда (күпфатирлы торак йортлардан кала) урнаштырылган мемориаль такталар башлап йөрүче тарафыннан бинаның хосусый милек хуҗасы (кулланучы) балансына күчерелә, яки аларны билгеләгән оешма балансына тапшырыла.
Күпфатирлы торак йортларда урнаштырылган мемориаль такталар башлап йөрүче тарафыннан күпфатирлы торак йортлар урнашкан шәһәр, авыл җирлеге Башкарма комитетлары балансына тапшырыла, яки аларны билгеләгән оешма балансына тапшырыла.

6.5. Балансларында мемориаль такталар булган шәһәр, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм оешмалар аларны саклау һәм карап тору чарасын күрәләр.

6.6. Мемориаль такталарны исәптә тоту һәм аларның торышын тикшерү җирләрендә яшәгән һәм эшләгән бөек кешеләр, монда урнашкан биналар, корылмалар һәм тарихи вакыйгалар булган истәлекле урыннар булган шәһәр, авыл җирлеге Башкарма комитетлары тарафыннан башкарыла.

6.7. Мемориаль такталарны салдыру турында карар (мемориаль такта урнашкан бинаны төзәтү эшләреннән кала) Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

**VII. Мемориаль такталарны проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыру чыгымнарын финанслау**

7.1. Мемориаль такталарны проектлаштыру, җитештерү һәм урнаштыру чыгымнарын юллама белән чыгыш ясаган як күтәрә.

7.2. Мемориаль такталарны җитештерүгә сатып алуларны зур иҗтимагый мәгънәгә ия булган монументаль сәнгать өлкәсендә иҗади проектларны югары сәнгать дәрәҗәсендә эшләү максатыннан Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты башкара, һәм җирле бюджет хисабына тулысынча яки өлешләп финанслый.

**VIII. Мемориаль такталарны саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык**

8.1. Мемориаль такталарны саклауда кагыйдәләрне бозган гәепле затлар гамәлдәге закончалык нигезендә җаваплы була.

8.2. Мемориаль такталарга зыян салган затлар аны элекке хәленә кайтарып төзәтергә, булдыра алмаган очракта гамәлдәге закончалыкка туры китереп зыянны капларга тиеш.